ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.11.2019 д. Канаш № 43

**Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2019 елның 6 ноябрендәге 2-1 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 4-1 номерлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Канаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Канаш авыл җирлеге башлыгы:** **Н. Н. Вальков**

Канаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 29 ноябрендәге
43нче номерлы карарына
1нче кушымта

**Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 мартына кадәр Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен түләү күләме гражданнар җыены турында карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары

д) балачактан инвалидлар

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүен (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашыруга яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм https://uslugi.tatarstan.ru/. муниципаль хезмәтләр порталы аша башкарыла.

8. Касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Канаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 29 ноябрендәге
43нче номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И. О. ____________________________________________________________________

Адресы: ______________________________________________________________

Сезгә _______________________________________нигезендә _____________________

вакытында кадәр _______________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр ________________ сум түбәндәге реквизитлар буенча_______________________________________ түләргә кирәк.

Алучының банк БИК ____________________________

Сч. № _____________________________

Алучының сч. № __________________________________

ИНН __________________________________

КПП __________________________________

КБК _______________ ОКАТО_____________

Түләү билгеләү ___________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________

(имза) (имзаны роасшифровкалау)

М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________

____________________________________________________________________

(муниципаль берәмлек исеме)

бюджетына үзара салым буенча ________________ суммада бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И.О. __________________________________

Адресы: ______________________________________________________________

Алган «__» ________________ 20__ ел__________________

( түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Аермалы кәгазь тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылса* ______________ *авыл җирлеге Башкарма комитетында кала .*